Кушымта

Салават күпере

Кадерле дускай!
Кушымтаны куш битләргә аер, аларның кисәсен кис, бөклисен бөклә. Бу эштә сиңа өлкәннәр ярдәм итәр.


My favourite ENGLISH

Минем яраткан инглиз телем





1 ДӘРЕС

Минем яраткан инглиз телем










Без Англиядән килгән дусларыбыз белән таныштык.
Ә хәзер аларның исемнәрен дөрес итеп әйтергә өйрәник әле.


Sam [‘сәм]
Ben [бэн]
Ann [‘ән]
Kate [‘кэйт]

I am [ай ‘эм]-мин
I am Ben [ай ‘эм бэн] -мин Бен





Бакый Урманче. Уралтау эргәсендә.



Автопортрет (1947)

Бакый Урманче
(1897-1990)

«Шигъриятебез» дигәндә, иң әүвәл Кол Гали, Габдулла Тукай исемнәре күңелебезгә килә. «Татар театры» диюгә, Габдулла Кариев, Галиәсгар Камал исемнәрен телгә алабыз. Милли музыкабыз хакында сүз алып барсак, күңел офыгыбызда Салих Сәйдәшев, Фәрит Яруллин пәйда була. Инде рәсем сәнгатенә килдек исә... Монда, әлбәттә, чишмә башыбыз – Бакый Урманче.

Бакый Идрис улы Урманче 1897 елның 23 февралендә дөньяга килә. Үз вакытында Казандагы атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала. Сабый чагыннан ук рәсем ясау белән мавыккан Бакый Урманче катмарлы язмышының сикәлтәле юлларыннан уза-уза мәшһүр әсәрләрен – искиткеч сурәтләрен, затлы таш сыннарын иҗат итә.



Шүрәле



Сагыш



Безнең аю бик тырыш—
Җыйган гөмбә бер тырыс!

КУРКАК ЮЛДАШ


Татар халык әкияте




Бервакыт ике кеше юлга чыккан. Боларга зур урман аша үтәргә туры килгән.




Кинәт болар каршында бер Аю пәйда булган.
Аюны күргәч, боларның берсе, куркып, агач башына үрмәләгән.



Икенчесе, үлгәнгә сабышып, тиз генә җиргә сузылып яткан.



Аю, җирдә яткан кеше янында иснәнгәләп йөргән-йөргән дә, аңа тимичә китеп барган.



Аю киткәч, агачтагы кеше җиргә төшкән.
– Аю синең колагыңа шыпырт кына нәрсә әйтте? – дигән ул иптәшенә.



Иптәше әйткән:
– Аю миңа, моннан соң шушындый куркак кеше белән юлга чыкма, дип әйтте, – дигән.













Ошбу рәсемнәрне кисеп алып, аларны әкиятнең эчтәлегенә туры килерлек итеп икенче биттәге шакмаклар өстенә куй (ябыштырсаң, тагын да әйбәтрәк булыр).

Аю белән Хатын

Татар халык әкияте

Әүвәлге заманда бер Хатын урак урырга баласы белән барган, ди. Ул ура башлагач ук, аның янына бер Аю килгән. Ул Аюның аягына шырпы кадалган икән, ди. Ул Хатынга аягын күрсәтергә килгән булган. Хатын аның аягыннан шырпысын алган. Шуның өчен Аю Хатынга бер умарта бал китереп биргән, ди.





Аю белән Бабай

Татар халык әкияте

Борын заманда Аю белән Бабай яшәгән. Алар, икәүләп, шалкан чәчкәннәр. Шалкан бик мул булып уңган.

Бабай Аюга:

– Син шалканның кай җирен аласың, тамырынмы, яфрагынмы? – дип сораган.

Аю хайваннарның яфракны яратып ашаганнарын күргән дә яфракка кызыккан.

– Мин шалканның яфрагын алам! – дигән. Һәм яфрагын алган. Бабайга шалканы калган.

Икенче елны Аю белән Бабай бодай чәчкәннәр. Быел инде Бабайдан алдатмам дип уйлаган Аю.

– Мин быел тамырын алам, ә син сабагын ал! – дигән ул Бабайга.

Бабай бодайны урып алган, ә Аюга камылы калган.

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ



Габдулла Тукай
(1886-1913)

Габдулла Тукай 1886 елның 26 апрелендә Кушлавыч авылында Мөхәммәтгариф мулла гаиләсендә дөньяга килә. Габдуллага 4 ай булганда әтисе, 3 яшь тә 9 ай чагында әнисе Мәмдүдә вафат була.

Ятим Апушның балачагы Кушлавыч, Өчиле, Кырлай авылларында һәм Казан, Җаек (Уральск) шәһәрләрендә уза.

Шагыйрь гомере, ни кызганыч, кыска була. Әмма шул кыска вакыт эчендә дә ул балалар өчен күп санлы әкият-поэмалар, шигырьләр, мәсәлләр иҗат итеп калдыра.

Г.Тукай 1913 елның 15 апрелендә кичке 8 сәгать 15 минутта күзләрен мәңгегә йома...

Шагыйрь һәрдаим күңелебездә саклана.



«Бишек җыруы»на иллюстрация. Рәссам Т.Хаҗиәхмәтов, 1981. Кәгазь, акварель, тушь.

Бишек җыруы

Әлли-бәлли итәр бу,
Мәдрәсәгә китәр бу;
Тыршып сабак укыгач,
Галим булып җитәр бу.

Йокла, угълым, йом күзең,
Йом, йом күзең, йолдызым;
Кичтән йокың кала да,
Егълап үтә көндезең.

Әлли-бәлли көйләрем,
Хикәятләр сөйләрем;
Сиңа теләк теләрем,
Бәхетле бул, диярем.

Гыйззәтем син, кадрем син,
Минем йөрәк бәгърем син;
Куанычым, шатлыгым
Тик син минем, синсең, син!


Колыбельная песня

Баю-баю-баю, сын,
В медресе поедет сын,
Все науки превзойдет,
Всех ученей будет сын.

Глазки сонные закрой,
Спи, мой месяц золотой,
Что не спишь ты по ночам,
Что ты плачешь день-деньской!

Баю-баюшки-баю,
Хочешь, песенку спою?
Стану сказки говорить,
Колыбель качать твою.

Спи, усни, бесценный мой,
Лучше всех ты, мой родной,
У меня на всей земле
Нету радости иной!



Габдулла ТУКАЙ


Ә хәзер үзеңнең исемеңне әйт әле?

I am...

Безнең яңа дусларыбызның исемнәре хәтереңдә калдымы? Таныш исемнәрне табып күрсәт.

Sam
Kate
Mary
Ted
Emma
Ben
John
Ann

Aa	Jj	Ss
Bb	Kk	Tt
Cc	Ll	Uu
Dd	Mm	Vv
Ee	Nn	Ww
Ff	Oo	Xx
Gg	Pp	Yy
Hh	Qq	Zz
Ii	Rr	



Минем яраткан инглиз телем

Aa


an apple
[эн ‘әпл]
алма



an ant
[эн ‘әнт]
кырмыска



an apricot
[эн ‘әприкот]
абрикос




Ә хәзер **Aa** хәрефен үзең язып кара әле! Башта әзер хәрефләр өстеннән каләмеңне йөртеп чык, аннары үзең язып бетер.

A A A ______

a a a ______

Хәтерләү өчен:
[ ]– сүзләрнең әйтелеше җәяләр эчендә.
‘ – басым билгесе иҗек алдына куела.

Дәресләрне югалтма, җыеп, теркәп бар.



Дәресне мөгаллимәләр Гүзәлия НӘҖИПОВА һәм Румия СӘЛИМУЛЛИНА алып бара.

